КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«03» октября 2022 156-п

Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эшчәнлегенең иң яхшы проектына конкурс уздыру турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган “2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш” дәүләт программасының “2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау” ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурс уздыру турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

“Татмедиа” республика
матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр
агентлыгының
2022 елның «03» октябре
156-п номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурс уздыру турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурс уздыру тәртибен билгели.

1.2. Конкурсның оештыручысы – “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык, Оештыручы);

1.3. Конкурс 1 декабрьгә кадәр үткәрелә.

1.4. Конкурсны үткәрү турындагы Оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар”, “Конкурслар һәм проектлар” бүлекләрендә урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурсны үткәрү шартлары, номинацияләр, конкурс эшләрен бәйләү критерийлары һәм тәртибе, гаризаларны кабул итү урыны, башлану һәм төгәлләнү сроклары, гаризаларны тапшыру тәртибе, бүләкләрнең күләме һәм рәвеше, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

1.5. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырыла.

1.6. Конкурска гаризаларның берсе дә кертелмәсә, Конкурс үткәрелмәде дип санала.

1.7. Конкурска бер генә гариза кертелсә, конкурс комиссиясе бу гаризаны әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегендә каралган тәртиптә бәяли.

## 2. Конкурсның төп максатлары, бурычлары, принциплары һәм номинацияләре

2.1. Конкурсның максаты – Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектларын ачыклау.

2.2. Конкурс үткәрүнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы муниципаль районнарының террорчылыкка каршы тору, аяулыкны арттыру, милли һәм дини нигезләрдәге каршылыкларга юл куймау зарурлыгы хакында аңлатма материалларны халыкка җиткерү буенча мәгълүмат-пропаганда төркемнәре эшчәнлеген стимуллаштыру;

- халыкта террорчылык идеологиясен күрәлмаучанлык тәрбияләү максатларында муниципаль берәмлекләрдә мәгълүмат бирү, агарту эш алып баруның яңа иҗади алымнарын куллану.

2.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү эше түбәндәге принципларга таяна:

гавамилык һәм Конкурс турындагы мәгълүматның ачыклыгы;

Конкурста катнашучыларның тигез хокуклы булуы;

ярышу рухы.

2.3. Конкурс «Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проекты» номинациясендә үткәрелә.

## 3. Конкурска гариза бирүчеләр һәм анда катнашучылар

3.1. Конкурска гариза бирүчеләр Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең проектын гамәлгә ашыра торган (ашырган) хокукка сәләтле физик затлар һәм юридик затлар. Хокукка сәләтле физик затлар конкурста катнашу өчен уртак гариза да бирергә мөмкин.

3.2. Конкурста катнашучылар – эшләре конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза тапшыручылар (алга таба – катнашучылар).

3.3. Конкурста катнашу гариза бирүчеләрнең конкурс эшләрен алга таба түләүсез, ләкин автор исемен һәм алынган чыганакны күрсәтеп, файдалануга (мәгълүмати, фәнни, уку-укыту өчен һәм мәдәни максатларда) ризалык бирүен аңлата.

3.4.Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән гариза бирүчеләргә (катнашучыларга) йөкләнә.

3.5. Гариза бирүче Конкурста катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

3.6. Гаризага бер генә Конкурс эше теркәлергә мөмкин.

## 4. Конкурсны үткәрү шартлары

4.1. Конкурска Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрү проектлары тәкъдим ителә.

4.2. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

а) конкурс эше – Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең гамәлгә ашырылган проектын тасвирлау. Конкурс эше текст, видеоролик, презентация рәвешендә булырга мөмкин.

б) Конкурста катнашу өчен анкета (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә);

в) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше буенча проект гамәлгә ашырылган Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (районнарындагы) һәм (яисә) шәһәр округындагы (округларындагы) мәгълүмат-пропаганда төркеменең (төркемнәренең) җитәкчесе (җитәкчеләре) бәяләмәсе (бәяләмәләре);

г) Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (районнарындагы) һәм (яисә) шәһәр округындагы (округларындагы) мәгълүмат-пропаганда төркеменең (төркемнәренең) проектны гамәлгә ашыруда катнашу дәрәҗәсен тасвирлаган белешмә (гариза бирүченең имзасы куелып);

д) физик затлар өчен:

шәхесне таныклый торган документ (күчермәсе);

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә Персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга ризалык бирү;

персональ белешмәләр субъекты рөхсәт иткән персональ белешмәләрне таратуга ризалык (3 нче кушымта);

Конкурста катнашу өчен уртак гариза тапшырган физик затлар өстәмә рәвештә конкурс эше призлы урын алган очракта акчаны процентлап бүлешү турында килешү тапшыра;

е) юридик затлар өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (күчермәсе) йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында теркәлү бите (күчермә);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);

гамәлгә кую документлары (күчермә).

әлеге пунктның «а» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазь вариантта (видеоролик рәвешендә башкарылган конкурс эше флешкартада тапшырыла) яисә сканердан чыгарып, PDF форматында электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.3.Конкурс эшләре Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә тапшырыла.

4.4. Конкурс эшләренә рецензия бирелми.

4.5. Гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт, 6 кат, 608 кабинет, ММЧ бүлеге, китереп тапшырырга, почта элемтәсе аша яисә электрон почта адресына (konkurs-ipg@yandex.ru) җибәрергә мөмкин. «Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурска» дигән тамга куелырга тиеш. Телефон: 8 (843) 570-31-12.

4.6. Документларның Агентлыкка килгән көне аларны тапшыру датасы дип санала.

4.7. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 4.1 – 4.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә гаризага әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында каралган документларны теркәмәү;

гаризаны Оештыручының рәсми сайтында күрсәтелгән срокны бозып тапшыру;

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләр тәкъдим итү.

4.8. Конкурска кертелмәгән эшләр, Оештыручының рәсми сайтында күрсәтелгән срокта кимчелекләре төзәтелеп, кабат тапшырылырга мөмкин.

4.9. Гаризалар кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң килгән эшләр каралмый.

4.10. Конкурс йомгаклары конкурс комиссиясе тарафыннан ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.11. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы Оештыручының рәсми сайтында өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

4.12. Оештыручы конкурс эшләрен киләчәктә үзе теләгәнчә файдаланырга мөмкин.

4.13. Гариза бирүчегә Конкурста катнашырга рөхсәт итү яисә рөхсәт итмәү турында хәбәр карар кабул ителгәннән алып бер эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе имзалаган һәм анкетада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы хат белән хәбәр ителә.

4.14. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һәм башка чыгымнар), гариза бирүчеләрнең (катнашучыларның) үзләре тарафыннан түләнә.

## 5. Конкурс комиссиясе

5.1. Конкурс комиссиясе составы Агентлык боерыгы белән 6 кеше составында раслана һәм комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан һәм әгъзалардан тора.

Комиссия секретарь Агентлык боерыгы белән билгеләнә, Комиссия составына керми, комиссия утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә торган урынбасарга йөкләнә

Комиссия секретаре Комиссия рәисе йөкләмәсе нигезендә Комиссия утырышларын оештыру функциясен башкара.

5.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышта башкарыла. Утырыш, әгәр анда әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

5.4. Комиссия:

- Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән конкурс эшләрен бәяли;
- Конкурста җиңүчеләрне билгели.

5.5. Комиссия әгъзалары җиңүчеләр билгеләнгәнгә кадәр Конкурста катнашучылар белән сөйләшүләр алып барырга тиеш түгел.

## 6. Конкурс эшләрен һәм Конкурста җиңүчеләрне бәяләү тәртибе

6.1. Конкурс эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

| № | Критерий | Баллар |
|---|---|---|
| 1 | Проектны гамәлгә ашыруда катнашкан кешеләр саны | 51 кеше һәм артыграк - 5 балл<br>41-50 кеше - 4 балл<br>31-40 кеше - 3 балл<br>21-30 кеше - 2 балл<br>11-20 кеше - 1 балл<br>10 кеше һәм кимрәк - 0 балл |
| 2 | Аудиторияне җәлеп итү | 100 001 кеше һәм артыграк - 5 балл<br>50 001- 100 000 кеше - 4 балл<br>25 001 - 50 000 кеше -3 балл<br>10 001 - 25 000 кеше - 2 балл<br>5001 - 10 000 кеше - 1 балл<br>5000 кеше һәм кимрәк - 0 балл |
| 3 | проектны гамәлгә ашырганда | интерактив эш - 5 балл |

| | | |
|---|---|---|
| | интерактив эш рәвешләрен куллану | интерактив эш булмау - 0 балл |
| 4 | Проектны электрон медиа – ресурсларда һәм басма матбугатта гамәлгә ашыру | Проектны электрон медиа – ресурсларда һәм басма матбугатта берьюлы гамәлгә ашыру - 5 балл<br>проектны электрон медиа – ресурсларда һәм басма матбугатта гамәлгә ашырмау - 0 балл |
| 5 | Проектны гамәлгә ашыруның дәвамлылыгы | 61 ай һәм күбрәк - 5 балл<br>49-60 ай - 4 балл;<br>37-48 ай - 3 балл<br>25-36 ай - 2 балл<br>13-24 ай - 1 балл<br>12 ай һәм кимрәк - 0 балл |

6.2. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс эшләрен әлеге Нигезләмәнең 6.1 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә бәяли. Һәр критерий буенча Комиссия әгъзасы тарафыннан куелган баллар суммасы конкурс эше комиссиясе әгъзасының бәяләмәсе булып санала. Комиссия әгъзаларының баллары суммасы конкурс эшенең йомгак суммасын тәшкил итә. Бәяләү балларыы буенча конкурс эшләре рейтингы төзелә. Конкурс эшләре рейтингы Комиссиянең йомгаклау беркетмәсендә теркәлә. Рейтинг нигезендә Комиссия конкурста җиңүчеләр исемлеген төзи.

6.3. Ике һәм күбрәк бертигез баллар җыйган катнашучылар булган очракта, җиңүче утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелеге тавышы белән билгеләнә. Тавышлар саны тигез булса, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

6.4. Конкурс эшләрен бәяләү нәтиҗәләре һәм Конкурсның җиңүчеләрен билгеләү төп беркетмәдә чагылыш таба, ул Конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана (Комиссия рәисе булмаган очракта беркетмәне Комиссия рәисе урынбасары раслый).

6.5. Төп беркетмәдә түбәндәгеләр теркәлергә тиеш:

- комиссия утырышында катнашкан һәр әгъза тарафыннан Конкурста катнашуга кертелгән һәр конкурс эшенә әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән һәр критерий буенча куелган баллар саны;

- Комиссия утырышында катнашкан һәр әгъзаны, Конкурста катнашуга кертелгән һәр конкурс эшенә куелган баллары;

- Конкурста катнашуга кертелгән һәр конкурс эшенә куелган балларның гомуми саны;

- Конкурста катнашуга кертелгән конкурс эшләренең куелган балларның гомуми санына карап, кимү бару тәртибендә формалаша торган конкурс эшләре рейтингы.

6.6. Конкурс эшләренең йомгак рейтингында 1, 2, 3 урын алган конкурс эшләре җиңүче дип танылa

6.7. Беренче урынны алган Конкурс эше ким дигәндә 90 балл җыярга тиеш.

Икенче урынны алган Конкурс эше ким дигәндә 80 балл җыярга тиеш.

Өченче урынны алган Конкурс эше ким дигәндә 70 балл җыярга тиеш.

6.8. Комиссия эшләрне бәяләгәннән соң һәм җиңүчеләр билгеләнгәннән соң биш эш көне эчендә Агентлыкның рәсми сайтында төп беркетмә урнаштырыла.

## 7. Финанслау

7.1. Конкурсны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган “2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш” дәүләт программасының “2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау” ярдәмче программасының 4.9.1 пунктын гамәлгә ашыру кысаларында финанслана

7.2.Конкурсның гомуми приз фонды 150,0 мең сум тәшкил итә.

7.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләклән:

| № | Номинация | Урын | Сумма |
|---|---|---|---|
| 1 | «Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проекты» | 1 урын | 60,0 мең сум |
| | | 2 урын | 50,0 мең сум |
| | | 3 урын | 40,0 мең сум |

7.5. Конкурста җиңүчеләр (җиңүче) булмаган очракта, әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган рәвештә, конкурста җиңүчеләрне (җиңүчене) бүләкләү өчен билгеләнгән акчалар бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурс уздыру турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурста катнашу өчен
АНКЕТА

Гариза бирүче
______________________________________________________________

Телефоны _______________________________________________

Проектны гамәлгә ашыру датасы
________________________________________________________________

Номинация
___________________________________________________________

Конкурска тапшырыла торган эшнең исеме
____________________________________________________________

Кыскача эчтәлеге

_________________________________________________________________

_________________________________________________________________

_________________________________________________________________

Адрес
_____________________________________________________________

Телефон/факс
______________________________________________________

e-mail
_____________________________________________________________

Эшләрне сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсына тәкъдим итү өченче затларның авторлык хокукын яисә башка хокукларын бозмый.

Дата ____________________
Имза ________________

*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурс уздыру турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________,
яшәү адресым_____________________________________________
__________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)_____________________
________________________________________________________________________
________________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурста катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.
Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

____________________________________________________________/______________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы)

_______________

(Дата)

---

*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурс уздыру турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)
______________________________________________________________________________,
(почта адресы)
______________________________________________________________________________,
(электрон почта адресы)
______________________________________________________________________________,
(телефон номеры)
“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Татарстан Республикасы муниципаль районында (районнарында) һәм (яисә) шәһәр округында (округларында) террорчылык идеологиясе таралуга каршы тору буенча халык арасында мәгълүмат бирү, агарту эше үткәрүнең иң яхшы проектына конкурста катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык | |
|---|---|---|---|
| | | Әйе | ЮК |
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Җенес | | |

1

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Гражданлык | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Шәхесне таныклаучы документ реквизитлары (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан бирелгән) | | |
| | Адрес | | |
| | Телефон номеры | | |
| | Электрон почта адресы | | |

2

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Персональ белешмәләрнең категориясе] | | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.
Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.
Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык _______________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне

туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.

Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

_______________(персональ белешмәләр субъекты имзасы)

_______________ (число, ай, ел)